| | |
|---|---|
| СОВЕТ ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

«21» гыйнвар 2022 ел с. Войкино № 26

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2003 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 31 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенддәге 1 өлешенең 20 пункты нигезендә

**Войкино авыл җирлеге советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» 2013 елның 07 июнендәге 71 номерлы Войкино авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- Базяково авылының, атап әйткәндә, түбәндәге адресы буенча урнашкан: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Войкино авыл җирлеге, Базяково авылы, Федин ур., 21й., үзәк өлешендә «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы» 1нче кушымтаның «Шәһәр төзелеше материаллары» IV нче кушымтасы кагыйдәләрендә (күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона) ОД1 территориаль зонасының бер өлешен (шәхси торак төзелеше зонасы) торак зонасына үзгәртергә. Үзгәртелгән территориаль зонаның гомуми мәйданы 4000 кв.м.
Әлеге территория зоналарын үз эченә алган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:05:060301:35; 16:05:060301:305
Әлеге территориаль зона урнашкан кадастр кварталы 16:05:060301
2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://alekseevskiy.tatarstan.ru урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

4. Карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Н.П.Шәбетдинова**